Раслыйм;
"Кояшкай" Биектау
балалар бакчасы мөдире
Г.Х.Зиннәтова
Приказ №18 01.09.2022 ел

# ***Татарстан Республикасы Балык-Бистәсе муниципаль районы Биектау авылы "Кояшкай" балалар бакчасының 2022 - 2023 уку елына укыту-тәрбия планы***

**Биектау авылы “Кояшкай” балалар бакчасының**
**2021-2022 нче уку елындагы эшчәнлегенә кыскача анализ**

2021 -2022 нче уку елында зурлар төркемендә барлыгы 14 бала, кечкенәләр төркемендә 11 тәрбияләнде. Ел дәвамында махсус урта белемле 2 педагог һәм югары белемле 2 педагог хезмәт куйды. Педагогларыбызның эш стажы 30 елдан артык.

Балалар бакчасында сәламәтләндерү чаралары дәвамлы үткәрелә. Иртәнге гимнастика, физкультура шөгыльләре, ашагач авызны чайкау, йокы алдыннан һәм йокыдан торгач массажлы юллардан йөрү, СанПин кагыйдәләрен исәпкә алып саф һавада булу системалы алып барыла.

Балаларыбыз өчен бакчада барлык уңай шартлар тудырырылган. Иң югары таләпләргә китерелеп эшләнгән уен почмаклары, спорт белән шөгыльләнү, музыка залы бар.

Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча тәрбияче Хуснуллина К.Ф. тарафыннан тематик-перспектив план төзелде. Шул план нигезендә тәрбиячеләр дәрес эшкәртмәләре төзеделәр. Шулай ук балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча табышмаклар, тизәйткечләр, такмаклар тупланды. Методик почмакта балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча шөгыльләр өчен кирәк булган күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, юл макетлары, светофор, юл билгеләре, рульләр, полиция формасы, юл күрсәтүче таяклар һ.б. тупланган. Тәрбиячеләргә, балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча ярдәмгә махсус әдәбият тупланган. Бу уку елында тәрбияче Хуснуллина К.Ф. Республика күләмендә уздырыла торган “Яшел ут” конкурсының муниципаль этабында катнашып 3 нче урын яулады.

Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата Федераль Дәүләт Белем бирү Стандартлары нигезендә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыруны максат итеп, ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, мультимедиа чараларын, УМКны киң кулландык.

Ел дәвамында тәрбиячеләр җитәкчелегендә балалаларыбыз төрле конкурсларда актив катнаштылар, призлы урыннар яуладылар. Республика күләмендә оештырылган “Буду бдительным на льду и на воде” рәсемнәр һәм видеороликлар конкурсының муниципаль этабында Шарифуллина Камилә, Шайдуллина Динә 2 урын, ә Валиева Алинә һәм Камасина Гөлүсәләр махсус грамотага ия булдылар. Шарифуллина Камилә һәм Якупова Нәзирә “Җәлил укулары” 4 нче халыкара әдәби бәйгенең муниципаль этабында катнаштылар. Якупова Нәзирә “Зимний пейзаж” исемле шигырь сөйләүчеләрнең региональ конкурсында 2 урынга ия булды.

Шулай ук балалар “Созвездие – Йолдызлык” фестивалендә актив катнаштылар, “Вокал – соло” номинациясендә дипломнарга ия булдылар. Татарстан балалар бакчалары арасында оештырылган конкурсларда да балалар актив катнашшып призлы урыннарга ия булдылар.

Муниипаль конкурсларда да балаларыбыз актив катнаштылар:
- « Я горжусь моей Родиной» конкурсында Шарифуллина Камилә, Шайдуллина Динә 1 урын,
- “Зеленая планета глазами детей” конкурсында Шайдуллина Динә 2 урын.

Тәрбиячеләр интернет челтәрләрендә уздырылган онлайн – форумнарда, семинарларда, вебинарларда катнаштылар. 1 педагог квалификация күтәрү курсларында белемен күтәрде.

Бакчабызның тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә әти – әниләр актив катнаша. Барлык чаралар алар катнашында оештырыла. Интернет челтәрләрендә оештырылган акцияләрдә (“Всемирный день памяти жертв ДТП”, “Международный день инвалидов», “Письмо водителю – родителю”, Бөек Җиңү көненә багышланган акцияләр) бакчабызда тәрбияләнүче балаларның әти-әниләре ярдәме бик зур.

“Кояшкай” балалар бакчасында укыту – тәрбия процессының, рухи-әхлакый тәрбиянең югары дәрәҗәдә куелуы һәм системалы алып барылуы балаларда әдәплелек, мәрхәмәтлелек, инсафлылык тәрбияли, аларны үз –үзләрен тота белергә, тирә яктагы матурлыкны күрергә, өлкәннәргә, иптәшләренә ярдәмчел, игътибарлы булырга өйрәтә. Белем бирү эшчәнлеге проектларны тормышка ашыру кысаларында алып барыла. Уку елы дәвамында түбәндәге проектларны тормышка ашырабыз:

“ Минем бакчам”, “Яшелчә, җиләк-җимешләр”, “Саубул җәй, исәнме көз!”
“Икмәк – яшәү терәге!” “Яхшы сүз- җан азыгы” “Дөнья матур- дөнья киң”
Табигать байлыклары “Су – яшәү чыганагы” “Минем өем, йорт җиһазлары”
“Мин дөньяның бер кешесе”
“Җәнлекләр” “Йорт хайваннары һәм кошлары”
“Безнең әниләр” “Кыш килде” “Бездә кышлаучы кошлар”
“Хәрәкәттә-бәрәкәт”

Куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнәбез “Могҗизалар илендә” (“Яңа ел бәйрәме”) “Сәламәтлек- зур байлык” “Юлда да акыл кирәк”

“Хезмәт төбе - хәзинә”
“Транспорт” , “Әхлак нигезе - матур гадәт”
“Батырлыкта - матурлык”
“Минем гаиләм, өем, авылым ” “Минем туган җирем”
“Милли киемнәр, бизәкләр”
“Россия- зур дәүләт”
“Безнең канатлы дусларыбыз”
“Бүлмә гөлләре” “Галәм киңлекләре” “Без язны яратабыз”
“Г.Тукай иҗаты” “Урман. Кызыл китап.”
“Җиңү көне”
“Чәчәкләр- тормыш яме”
“Сау бул бакча, исәнме – мәктәп”
“Исәнме, җәй!”

Түбәндәге бәйрәм иртәләре оештырылды:

“Өлкәннәрне зурлыйбыз!”

“Көз, сине көттек без!”

“Каз өмәсе” “Яңа ел бәйрәме”

“Ватанны саклаучылар көненә багышланган бәйрәм иртәсе

8 март – Халыкара хатын – кызлар көненә багышланган бәйрәм иртәсе “Әбиемнең күңел сандыгы”

“Бөек Тукайны зурлыйбыз!”

“Хуш, күңелле бакчабыз!”

“Сабантуй”

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, балалар бакчасында тәрбия-өйрәтү эше җитәрлек дәрәҗәдә куелган, балаларны өйрәтү, төрле яклап үстерү һәм тәрбияләү эшенә зур игътибар бирелә, уңай шартлар тудырылган.

**Әти-әниләр белән берлектә эшләнгән эшкә анализ:**

Уку елы башы белән әти –әниләр белән: “Балаң бакчага барырга әзерме ?”дигән темага тест үткәрелде.анда бирелгән сорау нәтиҗәләренең тиешле югарылыкта булуы ачыкланды. Өлкәннәр көне уңаеннан ,без балалар бакчасы хезмәткәрләре дә читтә калмадык. Шушы бакчада хезмәт куеп .лаеклы ялга чыккан апаларыбызны котлап бүләк –күчтәнәчләребезне өләштек. Өлкәннәребезнең моңа бик күңелләре булды. Һәр ике группада әти –әниләр җыелышы үткәрелде.Җыелышка участок инспекторы Якупов Айрат Илсур улы чакырылды.Ул барлык әти-әниләргә аңлаешлы итеп балалар куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәклеген,җиңел генә карамаска кирәклеген әйтеп үтте. Юлларда балалар белән булган хәвефләрнең һәрдаим булып торуын,ахыры аянычлы булып бетүе хакында да искәртеп үтте.Шулай ук авылыбыз фельдшеры Сабирова Миләүшә Гаяз кызы да әти-әниләребез алдында үзенең яңа авырулар хакындагы белемнәрен җиткерде.Быел әлеге вакытта маска режимы булуын,бер-беребезгә карата игътибарлырак булырга кирәклеген әйтеп үтте.Балаларның кулларын урамнан я булмаса башка кешеләр белән аралашканнан соң һәрвакыт сабынлап юарга кирәклеген азсызыклап үтте. Авыру ларны булдырмау йөзеннән әти-әниләребез белән берлектә бәйрәмнәрне үткәрмәскә тырыштык.”Көз” бәйрәме ,”Әниләр көне”,”Чыршы “ һәм ”8-март” бәйрәмнәре балалар белән бергә генә үткәрелделәр. Яңа балалар бакчасы салыну уңаеннан әти-әниләребез бик актив булдылар. Юып-җыю,җыештыру эшләрендә катнаштылар.Иске бакчадагы җиһазларны ташышып,аларны тиешле бүлмәләргә урнаштырдылар.Яңа җиһазлар кайткач аларны ташып урнаштырырга ярдәм иттеләр. Бакча ачылышында да активлыкларын

күрсәттеләр. Кышын кар көрәшергә дә ярдәм кулы сузды безнең әти-әниләребез.Төрле акцияләрдә актив катнашып килделәр. Балалар белән берлектә видео роликлар ясадылар.Төрле конкурсларда актив катнашып килделәр. Яңа ел уңаеннан төрле уенчыклар: Кар бабайлар,чыршылар ясап алып килделәр ,Алардан күргәзмә оештырдык. “Әниемнең күңел сандыгы” дигән темага үзләренең нәсел шәҗәрәләрен  ясадылар.Космонавтлар көне уңаеннан  “Серле күк йөзе” дигән тема астында төрле ясалма эшләр ясадылар,алардан күргәзмә оештырдык. Балаларның чыгарылыш кичәсен дә бик күңелле итеп үткәрергә ярдәм итте безнең әти-әниләребез.”Баларны яклау көне” уңаеннан үткәрелгән  акциядә дә әти-әниләребезнең активлыгын күрдек.

**Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту:**

Баланың  оптималь эшкә сәләтлелек халәте, аның үз-үзен яхшы хис итүенә, организмындагы барлык органнарның әйбәт эшләвенә нык бәйләнгән. Сәламәт бала эшчәнлекнең барлык төрләренә (интеллектуаль танып белү, хезмәт, иҗтимагый, физик культура, уен) рәхәтләнеп һәм шатланып катнаша. Ул - көр күңелле, яшьтәшләре һәм педагоглар белән җиңел аралаша.

Безнең кул астында- табигать үзе биргән сигез табиб бар. Алар:

Беренче табиб - кояш яктысы.

Икенче табиб — саф һава.

Өченче табиб - чиста су.

Дүртенче табиб- дөрес туклану.

Бишенче табиб - физик күнегүләр.

Алтынчы табиб - ял.

Җиденче табиб - гәүдәне дөрес тоту.

Сигезенче табиб — акыл.

Шуларны истә тотып, балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту балалар бакчасының төп бурычларының берсе булып тора. Нинди эшләр башкарылды соң безнең балалар бакчасында балаларның сәламәтлеген саклау өчен?

Балалар бакчасында эш тәрбиячеләрнең баланы иртән фильтр аша кабул итү белән башланып китә. Соңыннан балалар белән музыкаль залда иртәнге гимнастика уздырыла. Иртәнге гимнастика баланың иртәнге йокысыннан торганнан соң сулыш, кан йөрешен, нерв системасының тонусын нормалләштерә, ашказанындагы һәм организмдагы матдәләр алмашын үзләштертә. Көндәлек гимнастика, икенче төрле әйкәндә, зарядка, баланың физик һәм уйлау-фикерләү сәлатен үстерә, шулай үк ата-анасыннан соң кәефсез калган баланың кәефен күтәрә, шулай үк шук булган балаларны дициплинага өйрәтә, оялчан баланы активрак булырга ярдәм итә. Балаларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып, иртәнге гимнастиканың күнегүләр нормасы билгеләнә. Шулай ук музыка астында төрле хәрәкәтләр ясап, балаларны биетүләр оештырыла.

Гимнастикадан соң иртәнге аш ашатыла. Сәламәтлек өчен шулай ук кирәкле, чөнки балаларга иртән сөттә пешерелгән ботка бик файдалы: анда балалар организмы өчен кирәкле витаминнар күп.

Шөгыль вакытында, шөгыльнең тибына карап физкультминуткалар, хәрәкәтле уеннар, бармак уеннары, күзләр өчен гимнастика, релаксация оештырыла. Болар барысы да баланың сәламәтлеге өчен мөһим, ник дигәндә, алар бик тиз аралар, тизрәк уйныйсылары килә башлый, талчыгалар. Физкультминутка һәм уеннар кирәкле вакытта уздырылса, балалар армаячак һәм үзләрен кирәкле дәрәҗәдә тотачаклар.

Шөгыльләрдән соң, саф һавага чыгу оештырыла. Саф һавага чыгу һәм физкультура белән шөгыльләнү шулай ук балалар өчен бик мөһим. Саф һавада йөрү һәм физкультура баланың сулыш юлларын чистарта, физик яктан активлаштыра, иммунитетын күтәрә.

Балалар саф һава суларга чыгып киткәч, группа бүлмәләре җилләтелә. Бу шулай ук балаларның сәламәтлеген саклау максатыннан эшләнелә.

Урамнан кергәннән соң куллар юыла, ашаган саен авыз чайкатыла, чишенеп йокы бүлмәсенә сандаликлар белән кереп караватлары янында салына. Бу шулай ук сәламәтлекне саклау, балаларга карата сакчыл караш. Йокы бүлмәсе балалар йокларга ятканчы һаваландырыла һәм ярты сәгать кала ябыла.

Йокыдан соң балаларга төрле сәламәтләндерү процедуралары һәм күнегүләр уздырыла: сәламәтлек сукмагыннан йөриләр, һава чыныктыру ваннасы, куллар, аяклар, башлар, күзләр һәм башка органнар өчен күнегүләр уздырыла.

Балаларның сәламәтлекләрен саклау безнең төп бурычыбыз, шуңа күрә һәр балага индивидуаль якын килергә, аның сәламәтлеге турында кайгыртырга тырышабыз.

## Коллектив алдында торган бурычлар:

• Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту. Сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗлык тәрбияләү.

**• Уку- укыту методик кулланмаларына таянып, ике дәүләт теле - рус һәм татар телләрен өйрәтүдә эти-әниләрне җәлеп итү.**

- Мәктәпчәчә яшьтәге балаларга заманча тәрбия һәм белем бирүдә эти-әниләр белән тыгыз элемтә эшчәнлеген оештыру.

## Педагогик кадрлар

| № | Фамилиясе, исеме | вазыйфасы | Белеме | Катего- | Эш стажы |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | риясе | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Зиннатова Г.Х. | мөдир | югары | биләгән вазифага туры килү | 13 |
| **2.** | Хуснуллина К.Ф. | тәрбияче | Махсус урта | 1 | 36 |
| **3.** | Загриева М.И. | тәрбияче | Махсус урта | 1 | 36 |
| **4.** | Валиева Г.М. | тәрбияче | Махсус урта | 1 | 34 |
| **5.** | Нуриева З.М. | тәрбияче | Махсус урта | 1 | 34 |

## Педагогларның квалификация дәрәҗәсен күтәрү турында мәгълүмат

| № п/п | Ф.И.О. | Вазифасы | Белем күтәрү курслары | Аттестация узган һәм узарга тиеш вакыты | Категориясе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Хуснуллина К.Ф. | Тәрбияче | 2018 | 2017/2022 | 1 |
| 2. | Загриева М.И. | Тәрбияче | 2018 | 2017/2022 | 1 |
| 3. | Валиева Г.М. | Тәрбияче | 2018 | 2017/2022 | 1 |
| 4. | Нуриева З М. | Тәрбияче | 2018 | 2017/2022 | 1 |

## Тәрбиячеләрнең үзбелемен күтәрү буенча иҗади эш темалары

| № | Ф.И.О. | Темалары. |
|---|---|---|
| 1 | Хуснуллина К.Ф. | Балаларның сөйләм телен һәм уй-фикерләү сәләтләрен үстерү |
| 2 | Загриева М.И. | Балаларның танып белү сәләтләрен үстерү |
| 3 | Валиева Г.М. | Балаларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү |
| 4 | Нуриева З.М. | Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү |

## Экологик тәрбия

| айлар | Тәрбия чаралары | Күргәзмәләр |
|---|---|---|
| Август | Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү; төрле табигый материаллар җыю | |
| Сентябрь | “Көзге урманга экскурсия” | “Яфраклар” |
| Октябрь | “Бакчабызга көз килде” (“Уңыш” бәйрәме) | “Бу нинди могҗиза?!” (Төрле яшелчәләрдән күргәзмә) |
| Ноябрь | “Канатлы дусларга ярдәм итик?!”(Бездә кышлаучы кошлар) | “Минем кунакларым” (Җимлектәге кошларны рәсемгә төшерү) |
| Декабрь | Кышкы авыл буенча экскурсия | “Авылда кыш” (рәсем конкурсы) |
| Январь | “Җәнлекләр кышны ничек уздыра?” | Табигый материалдан ясалган әйберләрдән күргәзмә |
| Февраль | “Урманны саклыйк!” | Макулатура тапшыру |
| Март | “Кайтыгыз,кошкайлыр” | “Яз килә”(рәсем конкурсы) |
| Апрель | Елгада боз китүен күзәтү. | “Бозда сак бул” (рәсем конкурсы) |
| Май | Язгы урманга экскурсия. | |

## Физик тәрбия
## Сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү

| Айлар | Эш төрләре |
|---|---|
| Август | Участокта физкультура мәйданчыгын , спорт инвентарьларын яңарту |
| Сентябрь | Балаларның физик эшчәнлеген бәяләү; ”Көзге кросс” |
| Октябрь | Эстафета ярышлары “Уңышны җыеп ал” |
| Ноябрь | Хәрәкәтле уеннар көне ”Спорт бәйрәме” |
| Декабрь | Кышкы уеннар өчен төрле корылмалар төзү. |
| Январь | Һавада спорт бәйрәме. |
| Февраль | “Саф һавада йөрибез” Бакча тирәсендә чаңгыда прогулка. |
| Март | “Уңган кызлар,җитез егетләр”. Эстафета ярышлары. |
| Апрель | Инеш буена поход. Уен мәйданчыкларын җиһазлау. |
| Май | Балаларның физик эшчәнлеген билгеләү: “Язгы кросс” Урманга поход. |

## Әхлак тәрбиясе

## Патриотизм, гуманлылык, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү

| айлар | бәйрәмнәр | Әдәплелек дәресләре |
|---|---|---|
| Сентябрь | “Белем бәйрәме” | Табигатькә күз килде<br>(Туган җиргә,<br>табигатькә мәхәббәт тәрбияләү) |
| Октябрь | “Бакчабызга көз килде” | Өлкәннәргә хөрмәт күрсәтик. Һөнәрләр. |
| Ноябрь | “Дуслык белән көчле без” | 4 ноябрь- халыклар бердәмлеге көне<br>6 ноябрь- ТР<br>Конституциясе көне |
| Декабрь | “Яңа ел белән!”<br>( Әкияттә кунакта) | Халкыбыз йолалары,<br>милли бәйрәмнәре |
| Январь | “Юлда да акыл кирәк!” | Хезмәт төбе хәзинә |
| Февраль | “Батырлыкта матурлык” | Туган өем- туган җирем- туган илем<br>Ватанны саклаучылар көне |
| Март | “Кайтыгыз, кошкайлар!” | Кече туганнарыбыз.<br>Нәүрүз килә! |
| Апрель | “Космонавтика көне”<br>“Без Тукай оныклары” | 2 апрель- балалар<br>китабы көне<br>Сөекле туган телем |
| Май | “ Бөек Җиңү көне” | Табигатьтә үзеңне<br>тоту кагыйдәләре.<br>Матур җәй, кил безгә! |

## Ата- аналар белән эш

| № | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.<br><br>2.<br><br>3.<br><br>4<br><br>5. | "Белем бәйрәме"ндә катнашу<br><br>Күчмә папкаларда консультацияләр<br><br>Әти-әниләр катнашында календарь бәйрәмнәр уздыру<br><br>Әти-әниләр катнашында төрле күргәзмәләр оештыру<br><br>Авылның истәлекле урыннарына экскурсияләр оештыру | 1 сентябрь<br><br>Ел дәвамында<br><br>Ел дәвамында<br><br>Ел дәвамында<br><br>Ел дәвамында | Тәрбиячеләр,<br>Муз. Җитәкчесе<br>Тәрбиячеләр<br><br>Тәрбиячеләр<br>Муз.җитәкчесе<br><br>Тәрбиячеләр<br><br>Тәрбиячеләр |

## Педагогик киңәшмә

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. Яңа уку елына киңәшмә рәисе һәм сәркатиб сайлау.<br>2. 2022-2023 уку елына еллык эш план.<br>3. Тәрбиячеләрнең эш планнарын раслау.<br>4. Балаларны төркемнәргә күчерү. | август | Мөдир-Зиннатова Г.Х. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. Диагностика нәтиҗәләре<br>3. «Балаларны танып-белү үсеше аша әхлакый патриотик тәрбияләүгә заманча карашлар» | сентябрь | мөдир-Зиннатова Г.Х<br>тәрбияче Валиева Г.М<br>тәрбияче Хуснуллина К.Ф. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. «Уен- балаларның сөйләм телен үстерү чарасы»<br>3. мәктәпкәчә яшьтәге»<br>4. «Региональ компонентны исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерү»<br>5. Яңа елга зерлек | декабрь | Мөдир-Зиннатова Г.Х.<br>Валиева Г.М.<br><br>Хуснуллина К.Ф. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. «Сүрәтләр, таблицалар буенча сөйләргә өйрәтү».<br>3. Педагогларның һәм ата-аналарның балалар сөйләм телен үстерүдә үзара хезмәттәшлеге (туган тел) | январь | мөдир-Зиннатова Г.Х<br>Валиева Г.М.<br><br>Нуриева З.М. |
| 1. Үсеш программасына һәм еллык планга нәтиҗә<br>2. Балаларның диагностик нәтиҗәләре. | май | Валиева Г.М.<br>Валиева Г.М<br>Хуснуллина К.Ф. |

| | | |
|---|---|---|
| 3. җәйге чорга эш планын булдыру<br><br>4. «ФГОСны гамәлгә ашыру шартларында балалар бакчалары эшчәнлегендә сәламәтлекне саклау технологияләре» | | Загриева М.И. |

## Педагогик кадрлар белән эш

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| УМК буенча стендларны яңарту | Ел дэвамында | Мөдир Зиннатова Г.Х. |
| Уен почмакларын төрле атрибутлар белән тулыландыру | Ел дэвамында | |
| Юл йөрү кагыйдәләре почмагын тулыландыру | Ел дэвамында | |
| Бәйрәмнәргә әзерлек | Ел дэвамында | |
| Тәрбиячеләрнең төрле район, республика конкурсларында, семинарларда катнашуы | Ел дэвамында | |
| Дидактик уеннар, лэпбуклар булдыру | Ел дэвамында | |
| Тематик тикшерү (зурлар төркеме) “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү буенча белем бирү эшен оештыру” | декабрь | |
| Тематик тикшерү (зурлар төркеме) “Сюжет уенын оештыру” | апрель | |
| 1. Кузэту оештыру хэм уткэру. (зурлар)<br>2. Рәсем шөгыленә анализ (кечкенэлэр) | сентябрь | |
| 1. Кунел ачу (бэйрэм) нэтижэлелеген бэялэу. (зурлар)<br>2. Аппликация шөгыленә анализ (кечкенэлэр) | октябрь | |
| 1. Ана теле шөгыленә анализ -милли тәрбия (зурлар)<br>2. “ Кояшкай” балалар бакчасынын тематик кузэту.(кечкенэлэр) | ноябрь | |
| 1. Балалар тормышын , сэлэмэтлеген саклау очен шартлар булуы.(зурлар)<br>2. Ана теле шөгыленә анализ (кечкенэлэр) | Декабрь | |
| 1. Сөйләм теле үстерү шөгыленә анализ (зурлар)<br>2. «Кояшкай» балалар бакчасынын тематик кузэту акты. Ике группа да<br>Тема: «Әти- әниләр белән эш” | Январь | |
| 1. Әхлак тәрбиясе-аралашу культурасы | Февраль | |

| | | |
|---|---|---|
| (кечкенэлэр)<br>2. Физкультура шөгыленә анализ(зурлар) | | |
| 1. “Кояшкай” балалар бакчасының кечкенэлэр төркемендә үткәрелгән комплексны күзәтү акты. | Март | |
| 1. Балаларны уенчык һәм предметлар ярдәмендә сөйләргә өйрәтү.(кечкенэлэр)<br>2. Математика шөгыленә анализ (зурлар) | апрель | |
| **Зональ балалар бакчалары белән эшчәнлек** | | |
| Үткәреләсе чара | Үтәү вакыты | Җаваплы бакча |
| Әти-әниләр белән эшчәнлек | декабрь | Биектау “Кояшкай” балалар бакчасы |
| Балалар бакчасында әкият терапиясе куллану | февраль | Котлы Бүкәш “Дуслык” балалар бакчасы |
| Юл йөрү кагыйдәләре | Март | Зур Мәшләк “Шатлык” балалар бакчасы |
| Экологик тәрбия | апрель | Шомбыт “Малыш” балалар бакчасы |
| 1. Консультацияләр һәм әңгәмәләр | Ел дәвамында | Зиннатова Г.Х. |

## Производство киңәшмәләре

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. Киңәшмә рәисе һәм сәркатибы сайлау<br>2. Хезмәтне саклау, вакцинация<br>3. Антикоррупция эшчәнлеге<br>4. Янгын куркынычсызлыгы, эвакуация планын булдыру<br>5. Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында килеп чыккан бәхәсләрне җайга салу буенча комиссия әгъзаларын сайлау<br>6. Антитеррор эшчэнлеге буенча план | Август | Мөдир-Зиннатова Г.Х. |
| 1. Алдагы җыелыш карары үтәлеше<br>2. 2022-2023 нче уку елы өчен чираттагы ял графигын төзү.<br>3. Куркынычсызлык кагыйдәләре<br>4. “Иң матур бизәлешле Яңа ел мәйданчыгы” конкурсы. | декабрь | Мөдир-Зиннатова Г.Х. |
| 1. Алдагы җыелыш карары үтәлеше<br>2. Чираттагы яллар графигын карау<br>3. Җәйге чорда хезмәткәрләрнең эш бүленеше<br>4. Җәйге сәламәтләндерү чорында куркынычсызлык кагыйдәләре | май | мөдир-Зиннатова Г.Х |

## Әти-әниләр җыелышы

| Темасы | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| Кечкенәләр төркеме | | |
| 1. Әти-әниләр комитеты председателе һәм әгъзаләрен сайлау.<br>2. Балаларның көндәлек режимы<br>3. Балалар бакчасында адаптация чоры | сентябрь | Загриева М.И.<br>Нуриева З.М.<br>Загриева М.И. |
| 1. Сүзле уеннар кулланып балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү<br>2. Гаилә кыйммәтләре | апрель | Загриева М.И.<br>Нуриева З.М. |
| Зурлар төркеме | | |
| 1. Әти-әниләр комитеты председателе һәм әгъзаләрен сайлау.<br>2. Туган телебезне саклап калуда әти-әниләрнең роле<br>3. Әти-әниләр катнашуында сюжетлы-рольле уеннар булдыру | октябрь | Валиева Г.М.<br>Валиева Г.М.<br>Хуснуллина К.Ф. |
| 1. Балаларны рус теленә өйрәтүдә әти-әниләрнең роле<br>2. Балалар белән бергә уйнагыз<br>3. Мәктәп баскычы | апрель | Валиева Г.М.<br>Хуснуллина К.Ф.<br>Башлангыч сыйныф укытучысы |
| Гомуми әти-әниләр җыелышы | | |
| 1. Киңәшмә рәисе һәм сәркатибы сайлау<br>2. Үткән уку елына анализ һәм яңа уку елына бурычлар<br>3. ОРВИ, грипкка каршы прививкалар<br>4. Белем бирү мөнәсәбәтләре катнашучылары арасындагы низагны җайга салу буенча комиссия<br>5. “Юл йөрү кагыйдәләре” | сентябрь | Зиннатова Г.Х.<br>ФАП фельдшеры<br>Сабирова М.<br>Зиннатова Г.Х.<br>Полиция хезмәткәре |
| 1. Җәйге чорга эш планы.<br>2. Төркемнәрне берләштерү. | май | Валиева Г.М.<br>Зиннатова Г.Х. |

**Ата-аналар белән УМК буенча эш төрләре**

## (Работа с родителями по УМК)

| № п/п | Содержание | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Әти-әниләрне анкеталаштыру. Тема: “УМК ны кулланып рус телен өйрәтү” («Организация обучения русскому языку в детском саду с использованием УМК») | сентябрь |
| 2 | Күчмә папка оформить итү: “Рус телен өйрәнгәндә карау өчен киңәш ителә торган мультфильмнар исемлеге” («Перечень мультфильмов, рекомендуемых детям для просмотра, при обучении русскому языку») | октябрь |
| 3 | Җыр сүзләрен өйрәнү, көз һәм яңа ел бәйрәменә персонаж костюмнары әзерләү. (Разучивание слов, песен, приготовление костюмов персонажей к празднику осени, к Новому году) | октябрь, декабрь |
| 4 | Рәсем күргәзмәсе оештыру: “Рус телен өйрәнүдә гаилә ничек үз баласына ярдәм итә” (Выставка семейных рисунков «Как я помогаю своему ребенку в изучении русского языка») | январь |
| 5 | «Папы всякие важны»: рус телендә шигырьләр, җырлар өйрәнү | февраль |
| 6 | “Әниләр бәйрәме” (« Мамин праздник»)Бәйрәмгә хәзерлектә катнашу. Рус телендә шигырьләр, җырлар өйрәнү. ( Участие в подготовке праздника:<br>Разучивание стихотворений, песен на русском языке приготовление костюмов для праздника.) | март |
| 7 | Ачык шөгыльләр күрсәтү. (Провести открытые просмотры занятий.) | апрель |
| 8 | Күчмә папка ясау: “Баланың сөйләм телен үстерү” («Речевое развитие современного ребенка».) | апрель |
| 9 | Ата-аналар җыелышы үткәрү: Туган телебезне саклап калуда әти-әниләрнең роле | октябрь |
| 10 | Ата-аналар җыелышы: Балаларны рус теленә өйрәтүдә әти-әниләрнең роле | апрель |
| 11 | Ата-аналар соравы буенча консультацияләр оештыру. (Проводить индивидуальные консультации по вопросам родителей.) | Ел дәвамында |
| 12 | Ата-аналар өчен информацион стенд булдыру: «Изучаем русский язык», “Туган телдә сөйләшәбез”, “Авазларны уйнатып”, “ФДББС” | Ел дәвамында |
| 13 | Күчмә папка ясау: «Бармак уеннары” уртанчы төркемдә (“Пальчиковые игры» в средней группе.) | Ел дәвамында |
| 14 | Күчмә папка ясау: “Безнең яраткан шигырьләребез” зурлар-мәктәпкә хәзерлек төремендә. ( «Наши любимые стихотворения» в старшей- подготовительной группе.) | Ел дәвамында |
| 15 | Күчмә папка ясау: “Сөйләм теле өчен уеннар һәм уен күнегүләре” мәктәпкә хәзерлек төркемендә ( «Игры и игровые | Ел дәвамында |

| | | |
|---|---|---|
| | упражнения для развития речи» в подготовительной группе.) | |

**Биектау урта мәктәбе белән хезмәттәшлек итү**
**2022-2023 нче уку елы.**

| № | Эш төре | Вакыты | Жаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкә экскурсияләр һәм максатчан прогулкалар | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 2 | Яңа уку елы башланганда «Белем» бәйрәмендә катнашу. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 3. | Укытучылар коллективын һөнәри бәйрәмнәре белән котлау. | Октябрь | Тәрбиячеләр |
| 4 | Мәктәп белән таныштыру; класс, китапханә, спортзал,компьютер бүлмәсе. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 5 | I сыйныф укучыларының укулары белән кызыксынып тору, дәресләрендә булу. | Ел дәвамында | Педагогик коллектив |
| 6 | 1 нче сыйныф укучыларының «Әлифба» бәйрәмендә катнашып, котлау | Февраль | Тәрбиячеләр |
| 7 | Башлангыч сыйныф укытучыларын ата-аналар жыелышына, белем бирү эшчәнлекләренә чакыру, рәсемнәр күргәзмәсе. | Даими | Мөдир, тәрбиячеләр |
| 8 | Мәктәпнең хоккей мәйданчыгы белән таныштыру, хоккей ярышларын карарга алып чыгу. | Кыш айларында | Тәрбиячеләр |
| 9 | Балаларны мәктәпкә әзерләү һәм озату кичәсе уздыру « Сау бул бакча.» | Май | Тәрбиячеләр |

## <u>Администарив – хужалык эше</u>

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Бакча биләмәсендә уңайлы шатрлар тудыруга эшләр/косметик ремонт эшләре:биләмәдә, бинада/ | Июль, август | Мөдир |
| 2 | Төркемдәге мебельләр маркеровкасына анализ | Сентябрь | тәрбияче |
| 3 | Яңа җиһазлар, пособиеләр белән тәэмин итү | Ел дәвамында | Мөдир |
| 4 | Яңа уку елына әзерлек буенча оператив киңәшмә | Август | Мөдир |
| 5 | Яңа локаль актларны төзү, раслау | Ел дәвамында | Мөдир |
| 6 | Хезмәткәрләрнең эш һәм ял положениеләрен эшләү | Сентябрь /кирәге чыккан саен/ | Мөдир |
| 7 | Белем бирү курсларына баручыларга заявка бирү | Ел дәвамында | Мөдир |
| 8 | Төркемнәрнең санитар халәтенә рейдлар | Октябрь | Мөдир |
| 9 | Йомшак инвентарны, урын җирне, сөлгеләрне яңарту | Ел дәвамында | Завхоз |
| 10 | Инветаризация, гамәлдән чыгару, яңа мебелләр алу (шкафлар, өстәл, урындык) | Ел дәвамныда | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Кухняга, прачкага хезмәтне саклау комиссиясе рейдлары | Декабрь | мөдир |
| 12 | Төркемнәрдә күргәзмә материалларын яңартуда зәвыклы эшләүгә анализ | Квартал саен | Мөдир |
| 13 | Балалар бакчасын, биләмәне яңа елга бизәү һәм үткәрү | Декабрь | Мөдир, хезмәткәрләр |
| 14 | Яңа ел бәйрәмен үткәрүдә янгын куркынычсызлыгы буенча киңәшмә | Декабрь | Мөдир |
| 15 | Продукция складына ревизия, бирелгән продукциягә контроль, пищеблоктагы хезмәтне саклау халәте | Ел дәвамында | Мөдир |
| 16 | Санэпедемрежимның үтәлеше | Ел дәвамында | мөдир |
| 17 | Беренче яртыеллыкка авыручанлыкка анализ | Январь | мөдир |
| 18 | Тәрбиячеләрнең документларын тәртипләү | Ай саен | Тәрбиячеләр |
| 19 | Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен формалашуын күзәтү | Март | мөдир |
| 20 | Туклануның торышы буенча киңәшмә | Апрель | Мөдир, тәрбиячеләр |
| 21 | Территорияне тәртипләү, чәчәкләр утырту | Май-июнь | Хезмәткәрләр |
| 22 | Эвакуацияләр уздыру | Квартал саен | мөдир |